ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**11.01.2023ел**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 22**

«2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 11 декабрендәге 3113 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $160^1$ статьясындагы $3^2$ пунктының дүртенче абзацы нигезендә , Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 11 декабрендәге 3113 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында (алга таба - Исемлек) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле юллар исемлеге өстәргә:

| | |
|---|---|
| «802 117 14030 13 0000 150 | Шәһәр җирлекләре бюджетларына күчерелә торган гражданнарның үзара салым акчалары». |

2. 2. Әлеге карарның гамәлен 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

3. . Әлеге карарны ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе О.П. Дёгтевага йөкләргә.

ЗМР БК җитәкчесе вазифаларын башкаручы А.В. Старостин